КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 14 гыйнвар г.Казань № б-23

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларында чиратны кыскарту (профилактикалау) һәм әлеге оешмаларда өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның яшәү шартларын яхшырту максатларында:

Бу боерыкка теркәлгән 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасындагы социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда чиратны кыскарту (профилактикалау) буенча чаралар комплексын (алга таба – Чаралар комплексы) расларга.

2. Чаралар комплексын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:

тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча кысаларында Чаралар комплексы чаралары үтәлешен тәэмин итәргә;

Чаралар комплексында аларны үтәү өчен билгеләнгән сроклар эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар комплексы чаралары үтәлеше турында мәгълүмат кертергә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар комплексы үтәлеше турында гомумиләштерелгән мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А.Голикова тарафыннан расланган 2025 елның 31 мартындагы ТГ-П45-40958 номерлы 2026 – 2028 елларга Социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларга урнаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексында билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 7 июль, б-1509 нчы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 14 гыйнвар, б-23 нче
боерыгы белән расланды

2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасындагы социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларга урнаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексы

| Т/с | Чараның исеме | Көтелә торган нәтиҗә | Җаваплы башкаручылар | Үтәү срогы | Документ төре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| I. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына урнаштыру эшен камилләштерү чаралары | | | | | |
| 1.1. | Өлкән яшьтәге граждан-нарны һәм инвалидларны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларга урнаштыру буенча хокук мөнәсәбәт-ләрен җайга сала торган төбәк норматив хокукый актларны камилләштерү (кирәк булганда) | Өлкән яшьтәге граждан-нарны һәм инвалидларны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларга урнаштырганда психик тайпылышлары булган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү | Татарстан Республи-касы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2026 елның 31 декабренә кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| 1.2. | Өлкән яшьтәге граждан-нарга һәм инвалидларга ярдәм итүнең мөмкин булган төрле формалары | Ел саен кимендә 2 мәгъ-лүмат кампаниясе үткәрү | Республика «Татме-диа» матбугат һәм массакүләм коммуни-кацияләр агентлыгы, | 2026 елның 1 октябренә кадәр, алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 | Россия Федера-циясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | турында халык арасында мәгълүмат кампанияләре үткәрү | | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | елның 1 мартына кадәр | хат (мәгълүмати белешмә) |
| 1.3. | «Гериатрия» профиле буенча медицина ярдәме күрсәтүне оештыру чараларын камилләштерү:<br>күппрофильле клиникалар штатына гериатр табибын кертү;<br>гериатрия профилен исәпкә алып, гражданнарның диспансер күзәтүен вакытында һәм сыйфатлы үткәрүне контрольдә тоту;<br>гериатрия бүлекләре һәм кабинетлары челтәрен киңәйтү;<br>өлкән яшьтәге гражданнарда полипрагмазияне бетерү өчен «клиник фармакология» профиле буенча консультатив ярдәм оештыру | Өлкән һәм карт яшьтәге кешеләр арасында инвалидлыкны һәм үлем күрсәткечләрен киметү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш гериатр белгече, Республика гериатрия үзәге, медицина оешмалары җитәкчеләре | 2026 елның 1 октябренә кадәр, алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хат (мәгълүмати белешмә) |
| II. Социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларның матди-техник базасын ныгыту чаралары | | | | | |
| 2.1. | Социаль хезмәт күрсәтү | Стационар формада | Татарстан | 2026 елның | Татарстан |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | оешмалары биналарын капиталь ремонтлау программасын ел саен раслау | социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләрнең яшәү шартларын яхшырту | Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | 31 декабренә кадәр, алга таба – ел саен | Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы |
| III. Социаль хезмәт күрсәтү һәм тиешле сыйфатлы социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган оешмалар секторын үстерү өчен шартлар тудыру чаралары | | | | | |
| 3.1. | Психик бозылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү | Дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларны бергә яшәү хезмәте белән колачлау:<br>2026 ел – 10 кеше;<br>2027 ел – 12 кеше;<br>2028 ел – 15 кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2026 елның 1 октябренә кадәр, алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| IV. Стационарны алыштыручы технологияләрне үстерү чаралары | | | | | |
| 4.1. | Стационарны алыштыручы технологияләрне гамәлгә | | | 2026 елның 5 мартына кадәр, | Россия Федерациясе Хезмәт һәм |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | ашыру, шул исәптән: | | | алга таба – ел саен | социаль яклау министрлыгына хат (мәгълүмати белешмә) |
| 4.1.2. | психик тайпылышлары булган инвалидлар өчен бергә яшәп күнекмә алу | Бергә яшәп күнекмә алу хезмәте белән колачлау 2026 ел – 80 кеше; 2027 ел – 80 кеше; 2028 ел – 80 кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе | | |
| 4.1.3. | дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә психик тайпылышлары булган инвалидлар белән бергә яшәү | Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә психик тайпылышлары булган инвалидларны бергә яшәү хезмәте белән колачлау 2026 ел – 6 кеше; 2027 ел – 12 кеше; 2028 ел – 18 кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | |
| 4.1.4. | өлкән кеше өчен тәрбиягә алган гаилә | Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар форма- | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган, хокукка сәләтле өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр саны:<br>2026 ел – 25 кеше;<br>2027 ел – 25 кеше;<br>2028 ел – 25 кеше | эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | |
| 4.1.5. | халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре базасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен көндезге бүлекләр (төркемнәр) | Ел саен көндезге бүлекләрдә (төркемнәрдә) социаль хезмәтләр күрсәтүгә 1 меңнән артык кеше җәлеп итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | |
| 4.2. | Озак вакыт карауны, «Карау буенча ярдәмче» хезмәтләрен кертеп, өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны өйдә карауны үстерү, дәүләтнеке булмаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә субсидияләр бирү | Өйдә социаль хезмәт күрсәтүгә / шул исәптән озак вакыт карауга җәлеп итү:<br>2026 ел – 16 меңнән артык кеше / 6 093 кеше;<br>2027 ел – 16 меңнән артык кеше / 6 098 кеше;<br>2028 ел – 16 меңнән артык кеше / 7 345 кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2026 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| 4.3. | Татарстан Республикасында стационарны алыштыручы технологияләрне | Мәгълүмати белешмә | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү | 2026 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | гамәлгә кертү практикасы турында мәгълүмат әзерләү | | һәм социаль яклау министрлыгы | ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | министрлыгына хат (мәгълүмати белешмә) |
| 4.4. | Өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру | Мохтаҗлар саныннан 100% өлкәннәрне һәм инвалидларны өйдә паллиатив медицина ярдәме белән колачлау | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 2026 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хат (мәгълүмати белешмә) |
| V. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар оешмаларына гражданнарның чиратын киметү (профилактикалау) эшчәнлеген координацияләү | | | | | |
| 5.1. | Торак урыннар мәйданы белән тәэмин итү нормативларын бозып, социаль хезмәт күрсәтүче стационар оешмаларда, шулай ук авария хәлендәге һәм тузган биналарда урнаштырылган социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр санын киметү | Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда, торак урыннар мәйданы белән тәэмин итү нормативларын бозып, шулай ук авария хәлендәге һәм тузган биналарда урнаштырылган социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләр булмау | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2026 елның 1 мартына кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хат (мәгълүмати белешмә) |
| 5.2. | 2026 – 2028 елларга стационар оешмаларга урнаштыру өчен өлкән гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү | Аналитик белешмә | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2027 елның, 2028 елның 1 мартына кадәр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хат (мәгълүмати |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | (профилактикалау) буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту | | | | белешмә) |